КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 февраль г.Казань № 157

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 декабрь, 1300 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2022 елда» сүзләрен «2022 – 2023 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән аерым чараларны гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 18 мартындагы 409 номерлы һәм «2023 елда хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән аерым чараларны гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 15 декабрендәге 2309 номерлы карарларын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 елда сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру өлешендә Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча «Демография» илкүләм проектының «Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм аларның нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану тәртибе;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2022 – 2023 елларда сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган 2022 елда сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022 – 2023 елларда сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибе»;

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән аерым чараларны гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 18 мартындагы 409 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 18 мартындагы 409 номерлы карары)» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән аерым чараларны гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 18 мартындагы 409 номерлы һәм «2023 елда хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән аерым чараларны гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 15 декабрендәге 2309 номерлы карарлары (алга таба – шул ук эзлеклелектә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 18 мартындагы 409 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 декабрендәге 2309 номерлы карары)»;

3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидия бирү максаты – хезмәткәрләрне укытуны оештыруга эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау). Эш бирүче, укыту чыгымнары кыйммәтенең нигезле булуын исәпкә алып, хезмәткәрләрнең укуын мөстәкыйль оештыра.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында яки Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегендә тиешле елга «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча каралган бюджет ассигнованиеләре күләме һәм

бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасы белән баш эш итүче буларак Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) тиешле елга билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

8 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүчеләр чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик затлар, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

10 пунктның алтынчы абзацында татар текстында «карары белән» сүзләреннән соң «2022 елга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 декабрендәге 2309 номерлы карары белән 2023 елга» сүзләрен өстәргә;

17 пунктта:

бишенче абзацта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 18 мартындагы 409 номерлы карары белән билгеләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

унөченче абзацта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 18 мартындагы 409 номерлы карары белән билгеләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

19 пунктның алтынчы абзацында «2022 ел» сүзләрен «тиешле ел» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия биргәндә планлаштырыла торган субсидия бирү нәтиҗәләре – заявкада күрсәтелгән хезмәткәрләрнең санына тигез булган, укуны тәмамлаган хезмәткәрләр саны һәм укуны тәмамлаган хезмәткәрләр санынннан уку тәмамланганнан соң эш белән тәэмин ителгәннәр өлеше кимендә 85 процент.

Чыгымнарны каплауга субсидия биргәндә ирешелгән субсидия бирү нәтиҗәләре – заявкада күрсәтелгән хезмәткәрләрнең санына тигез булган, укуны тәмамлаган хезмәткәрләр саны һәм укуны тәмамлаган хезмәткәрләр саныннан уку тәмамланганнан соң эш белән тәэмин ителгәннәр өлеше 100 процент.»;

25 пунктның дүртенче абзацында «2022 ел» сүзләрен «тиешле ел» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга 2023 елда сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру өлешендә Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә

чараларны тормышка ашыру буенча «Демография» илкүләм проектының «Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм аларның нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 23 март, 257 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 18 февраль, 157 нче
карары редакциясендә)

2023 елда сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны
һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру өлешендә Татарстан Республикасы
хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны
тормышка ашыру буенча «Демография» илкүләм проектының «Халыкның
эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына,
күрсәткечләренә һәм аларның нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк
проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы
чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә
бирелә торган акчаны файдалану
тәртибе

1. Бу Тәртип 2023 елда сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы (тулы булмаган эш вакыты режимын кертүне, эшләрне туктатып торуны, вакытлыча туктатуны, хезмәт хакын сакламыйча яллар бирүне, хезмәткәрләрне эштән азат итү чараларын үткәрүне кертеп) хезмәткәрләрен (алга таба – хезмәткәрләр) һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру өлешендә Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча «Демография» илкүләм проектының «Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм аларның нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансферт) рәвешендә бирелә торган акчаны 2023 елда файдалану механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансферт Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) ачылган Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетына керә.

3. Башка бюджетара трансфертны тоту бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм башка бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәре турында мәгълүмат алганнан соң җиде эш көне эчендә башка бюджетара

трансфертны финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) җиткерә.

5. Министрлык Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан башка бюджетара трансфертның иң чик финанслау күләмнәре турында мәгълүмат алган көннән җиде эш көне эчендә башка бюджетара трансфертның иң чик финанслау күләмнәрен Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) булган, Министрлык тарафыннан билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә хезмәткәрләрне укыту чараларын тормышка ашыручы казна учреждениеләренә җиткерә.

6. Бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән акча халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан эш бирүчеләрнең хезмәткәрләрне укытуны оештыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) җибәрелә.

7. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, үзләренә билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә һәм аларның счетына акча керүгә карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карары белән расланган 2022 – 2023 елларда сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибе нигезендә акчаны субсидияләр рәвешендә эш бирүчеләр счетына күчерә.

8. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5 нче көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Министрлык тарафыннан билгеләнгән форма буенча Татарстан Республикасы бюджетының финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнары турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап тапшыра.

Министрлыкка тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә йөкләнә.

9. Министрлык, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру өлешендә Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча «Демография» илкүләм проектының «Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм аларның нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансферт бирү турындагы килешүдә (алга таба – Килешү) билгеләнгән башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү өчен җавап бирә.

10. Министрлык түбәндәге хисапларны Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин

итү федераль хезмәтенә тапшыра:

а) финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап – ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 5 санынннан да соңга калмыйча;

башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында – Килешүдә каралган форма буенча һәм срокларда.

Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык Министрлыкка йөкләнә.

11. Башка бюджетара трансфертны максатчан файдаланмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

12. Әгәр 2023 елның 31 декабренә кадәр Килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәлгән һәм башка бюджетара трансферт бирелгән елдан соң килә торган елда Килешү нигезендә башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшырыла торган беренче датага кадәрге срокта әлеге бозулар бетерелмәгән булса, 2024 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджетка кире кайтарылырга тиешле акча күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2023 елда хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән кайбер чараларны гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 15 декабрендәге 2309 номерлы карары белән расланган, Россия Федерациясе субъектлары хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча «Демография» илкүләм проектының «Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм аларның нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә исәпләп чыгарыла.

13. Бу Тәртип нигезендә бирелгән акчаны максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.